**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
**IV чакырылыш чираттан тыш утырыш**
**“16"август 2023 ел №37 Урыссу ш.т.п.**

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 26.06.2018 № 18 карары белән расланган, Ютазы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә һәм даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларына күпьеллык хезмәтләре өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 26.06.2018 № 18 карары белән расланган, Ютазы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә һәм даими нигезндә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларына күпьеллык хезмәтләре өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булу, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукы бирә торган яшькә җитеп, муниципаль хезмәттән азат ителү яки «Иминият пенсияләре турында» 28.12.2013 ел, №400-ФЗ Федераль закон нигезендә, инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнү аңлашыла.

Бер тапкыр түләнелә торган бүләкләү түләнми:

- эштән азат ителгән вакытка дисциплинар җәзасы булган муниципаль хезмәткәргә;

- тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгу сәбәпле, законнар нигезендә бер мәртәбә түләнә торган бүләкләү муниципаль хезмәткәргә инде түләнгән булса;

- муниципаль хезмәттән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган хокук бозулар кылу сәбәпле азат ителгәннәргә.».

1.2. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татартсан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин